2014 елнын 3 нче декабрендә илебездә беренче тапкыр «Билгесез солдат Коне» билгеләп vтелде.
Россия Дәvләт Советы депутатлары тәкъдиме белән тарихи дата итеп билгеләнгән «Билгесез солдат Коне» - яу кырларында башларын салып, исемнәре ачыкланмый калган сугышчыларны - Ватаныбыз улларын искә алу, аларнын батырлыгы алдында баш иеп, хәтерләрне янарту ул.   1966 елнын 3 декабрендә, Мәскәv астында немец гаскәрләрен тар-мар итvгә 25 ел тулу унаеннан, Александровский бакчасында тантаналы рәвештә билгесез солдат коле жирләнә. Аны Зеленоград шәһәренә керv юлында урнашкан туганнар каберлегеннән кvчергәннәр. 1967 елда Александровский бакчасында мәнгелек ут кабызыла һәм «Штыки» мемориаль комплексы ачыла.
Боек Ватан сугышынын илгә кvпме югалтулар алып килvе турында ачынып сойлибез. Кvпме якташларыбыз яу кырыннан кайта алмаган, ә кvпмеләре әле хәзер дә хәбәрсез югалганнар исемлегендә йори. Мәнгелек ут һәм һәйкәл янына чәчәкләр Рузаевка районы Татар Пешлә авылы администрациясе белән Мәдәният йорты вәкилләре, Татар Пешлә урта мәктәбе директоры Флора Әхмәтжан кызы Шамонова житәкчелегендә 5 (класс житәкчесе Сания Спартак кызы Саляева), 10 (класс житәкчесе Светлана Федоровна Медведева), 11 (класс житәкчесе Елена Сергеевна Рахмукова) сыйныф укучылары сугышта башларын салган геройларны бер минут тынлык белән искә алганнар, мәнгелек ут янына гвоздикалар салганнар. Шуннан сон барлык класс житәкчеләре укучыларына Билгесез солдат батырлыгы турында, презентацияләр кулланып, чаралар vткәргәннәр. Сания Спартак кызыннан нәрсә турында сойләден дип сорагач: